**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 9 декабрендәге 5084 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2023 елның 25 декабрендәге 4319 номерлы**
**«Казан шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын тәэмин итү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак (вафат) булган гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында»гы карары нигезендә, аерым категорияләргә караган гражданнарга өстәмә ярдәм күрсәтү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 25 декабрендәге 4319 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын тәэмин итү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2 пунктчаның унынчы – унҗиденче абзацларын түбәндәге редакциядә бирергә:

«- ике тапкыр кайнар ризык белән – 1-11 сыйныф укучыларын – түбәндәге гражданнар арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзаларын, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнары гаиләләрендә тәрбияләнүче, ирнең (хатынның) беренче (башка) гаиләсендә туган балаларны:

а) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар;

б) Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер»

батальоннарында хәрби хезмәт узучылар;

в) махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларын ирекле рәвештә башкаручы гражданнар;

г) махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән хәрби хезмәткәрләр һәм Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче затлар;

д) махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре;

е) махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак (вафат) булган Россия Федерациясе гражданнары;

- 1-11 сыйныф укучыларын – карарның әлеге пункты белән билгеләнгән гражданнар арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның өйдә белем алучы гаилә әгъзаларын – составы Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең боеру акты нигезендә раслана торган азык-төлек җыелмасы белән (айга бер тапкыр)»;

1.2. 6.2 пунктчада «балаларына» сүзен «гаилә әгъзаларына» сүзләре белән алмаштырырга;

1.3. 4 номерлы кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.4. әлеге карарга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 25 декабрендәге 4319 номерлы карарына 4 номерлы кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 9 декабрендәге
5084 номерлы карарына
кушымта
(Форма)

Казан шәһәре ________________________
__________________________ районының
_____ номерлы мәктәбе/гимназиясе/лицее
(кирәклесенең астына сызарга)
укучыларының туклануын оештыру
комиссиясенә

___________________________________
__________________________________,
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме,
атасының исеме)
адресы:_____________________________
___________________________________
___________________________________

бушлай туклану белән тәэмин итүгә гариза.

Минем улымны/кызымны/тәрбиягә алган баламны (кирәклесенең астына сызарга) ______________________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
______ сыйныф укучысын, бушлай туклану белән тәэмин итүегезне сорыйм.

Нигезләү (кирәклесенең астына сызарга):

- сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле бала;

- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның баласы (гаилә әгъзасы____________________);
(кем икәнен күрсәтергә)

- махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак (вафат) булган Россия Федерациясе гражданнарының баласы (гаилә әгъзасы______________________);
(кем икәнен күрсәтергә)

- махсус хәрби операциядә катнашучы һәм хәрби хезмәткәрләр һәм Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче затлар булып торучы гражданнарның баласы;

- Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарның баласы;

- махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларын ирекле рәвештә башкаручы гражданнарның баласы;

- махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең баласы;

- бала – Украина, Донецк һәм Луганск халык республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләре территорияләрен калдырып китәргә мәҗбүр булган һәм Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч тәртиптә күпләп килгән Украина гражданины, Донецк һәм Луганск халык республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләре гражданины яки Украина, Донецк һәм Луганск халык республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләре территорияләрендә даими яшәгән гражданлыгы булмаган зат.

Өстәмә рәвештә хәбәр итәм: _____________________________________________________.

____________________ (дата) ____________________________ (имза)

__________________